ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон “Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук парковкалар эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыруны хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыруны хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм аларга таянып кабул ителә торган Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә Россия Федерациясенең дәүләт сәясәте нигезендә Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтле органын билгеләү (алга таба – вәкаләтле башкарма хакимият органы);

3) юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

4) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру чараларын гамәлгә ашыру буенча эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты финанс чыгымнарының Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында каралган методика нигезендә билгеләнгән нормативларын раслау;

5) Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган методик рекомендацияләр нигезендә региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасын, шулай ук аның максималь күләмен билгеләү;

6) юл хәрәкәтен оештыруның региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен эшләнә торган проектларын килештерүче органнар һәм оешмалар исемлеген билгеләү;

7) юл хәрәкәтен оештыруның муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге йә аларның өлешләре территориясе өчен, шулай ук уртак чикләре булган берничә муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге территорияләре өчен эшләнә торган комплекслы схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген билгеләү;

8) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру һәм мониторинглау;

2) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыру, алмаштыру, сүтү һәм карап тоту;

3) гомуми файдаланудагы парковкалар реестрын алып бару тәртибен билгеләү;

4) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан гомуми файдаланудагы парковкалар реестрын алып бару;

5) Федераль законның 18 статьясындагы 8 өлеше нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен эшләнә торган проектларын раслау;

6) юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру;

7) Федераль закон һәм әлеге Закон белән вәкаләтле башкарма хакимият органы вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм вәкаләтле башкарма хакимият органы юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә үз вәкаләтләрен турыдан-туры яисә алар вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешмалар аша гамәлгә ашыралар.

5 статья. **Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә муниципаль районнарның, шәһәр округларының һәм шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру һәм мониторинглау;

2) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында гомуми файдаланудагы парковкалар реестрын алып бару;

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыру, алмаштыру, сүтү һәм карап тоту;

4) Федераль закон белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Җирле үзидарә органнары юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә үз вәкаләтләрен турыдан-туры яисә алар вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы оешмалар аша гамәлгә ашыралар.

6 статья. **Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең, җирле үзидарәнең юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтле органнары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру чараларын гамәлгә ашыру ярдәмендә башкарыла, аларга түбәндәгеләр керә:

1) транспорт чаралары хәрәкәтен транспорт чаралары категорияләренә, хәрәкәт тизлегенә һәм юнәлешенә карап бердәй төркемнәргә бүлүне дә кертеп,

юлларда транспорт чараларын бүлүгә идарә итү, аларны хәрәкәт вакыты буенча бүлү;

2) юлларның үткәрү мөмкинлеген арттыру, шул исәптән юл хәрәкәтенә тоткарлыклар тудыруга китерә торган яисә аның иминлегенә яный торган шартларны бетерү, бозралы кисешү урыннарын һәм юлларның кушылуын булдыру, юл чатларын реконструкцияләү һәм транспорт киселеше юлларын төзү ярдәмендә;

3) светофор белән җайга салу циклларын оптимальләштерү, светофор объектларына идарә итү, җайлаштыра торган идарә итүне дә кертеп;

4) юл хәрәкәтен оештыру документларында билгеләнгән территорияләр чикләрендә светофор объектларының (светофорларның) эшләвен килештерү (координацияләү);

5) җәяүлеләрнең һәм велосипедта йөрүчеләрнең хәрәкәтен тәэмин итү максатларында инфраструктураны үстерү, шул исәптән җәяүлеләр өчен юл аша чыгу урыннарын төзү һәм җиһазлау;

6) маршрут транспорт чаралары хәрәкәтендә өстенлек кертү;

7) парковка мәйданнарын арттыру (бигрәк тә юллардан читтә);

8) транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү яисә аны вакытлыча туктату.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең, җирле үзидарәнең юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтле органнары юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чараларын әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, зарурлыгы нигезләве юл хәрәкәтен оештыру документларында булган гамәлләрне башкару ярдәмендә күрергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тиешенчә региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү максатларында билгеле бер төрдәге (типтагы), категориядәге, экологик класстагы транспорт чараларына, аларның пассажирлар белән тулы булуына карата, шулай ук билгеле бер көннәргә һәм тәүлек вакытына карата транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертергә яисә аны вакытлыча туктатырга хокуклы.

4. Юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү максатларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү яисә аны вакытлыча туктату турында карар кабул ителгән очракта, юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтле башкарма хакимият органы, вәкаләтле җирле үзидарә органнары халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән компенсация чаралары (даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларының эшләү сыйфатын арттыру, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның яңа маршрутларын ачу яисә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның гамәлдәге маршрутларының пассажирлар йөртү һәм багаж ташу мөмкинлекләрен арттыру, парковкалар (парковка урыннары) оештыру, велосипедта йөрүчеләрнең хәрәкәтен тәэмин итү максатларында инфраструктураны үстерү, башка шундый чаралар) күрергә тиеш.

7 статья. **Түләүле парковкалар урнаштыруны тыю**

Түләүле парковкаларны белем бирү оешмалары, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системаларының медицина оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтләре, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар урнашкан биналар янәшәсендәге территорияләрдә, шулай ук торак законнары нигезендә күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә караган җир кишәрлекләрендә урнаштыру тыела.

8 статья. **Түләүле парковкадан түләүсез файдалану хокукы**

1. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан түләүле парковкалар түбәндәге очракларда түләүсез файдаланыла:

1) эш көннәрендә һәм шимбә көннәрендә җирле вакыт буенча 21 сәгать 00 минуттан алып 7 сәгать 00 минутка кадәр;

2) транспорт чарасы 15 минуттан да күбрәк булмаган вакытка туктап торганда;

3) ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә.

2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан түләүле парковка хуҗасы әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында билгеләнгән мондый түләүле парковка түләүсез файдаланыла торган вакытны арттырырга хокуклы.

3. Түләүле парковкадан файдаланган өчен түләү алу, Федераль законның 13 статьясындагы 8 өлешендә каралган транспорт чараларыннан тыш, I, II төркем инвалидлары, шулай ук III төркем инвалидлары идарә итә торган транспорт чараларына һәм мондый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чараларына карата да рөхсәт ителми. Күрсәтелгән транспорт чараларына вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә бирелгән “Инвалид” тану тамгасы куелырга тиеш.

4. Түләүле парковка хуҗасы түләүле парковкадан түләүсез яисә ташламалы файдалану хокукы бирелә торган түләүле парковкадан файдаланучыларның, транспорт чараларының өстәмә категорияләрен билгеләргә хокуклы.

5. Инвалидлар идарә итә торган, шулай ук инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чаралары юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә махсус юл йөрү билгеләре һәм (яисә) тамгалау белән билгеләнгән урыннарда урнаштырыла. Күрсәтелгән парковка урыннарында башка транспорт чаралары урнаштырылырга тиеш түгел.

9 статья. **Түләүле парковкалар булдыру һәм алардан файдалану турында карарны әзерләү хакында халыкка хәбәр итү**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары үзләре тарафыннан түләүле парковкалар булдыру һәм алардан файдалану

турындагы карарны әзерләү хакында халыкка рәсми материалларны һәм хәбәрләрне, норматив хокукый һәм башка актларны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) өчен дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган вакытлы матбугат басмаларында тиешле мәгълүматны, шулай ук үзләренең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында түләүле парковкалардан файдалана башлауга кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча түбәндәге мәгълүматны урнаштырып хәбәр итәргә тиеш:

1) түләүле парковкалардан файдалану зарурлыгын нигезләүне, гомуми файдаланудагы парковкалардан файдаланган өчен түләү кертү ярдәмендә юл хәрәкәте өлкәсендә хәл ителүе планлаштырыла торган төп проблемаларны;

2) түләүле парковкалардан файдалана башлау датасын;

3) Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек территориясендә булдыру күз алдында тотылган түләүле парковкалар зоналарын;

4) түләүле парковкалардан файдалану тәртибен;

5) парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен һәм аны башкару тәртибен.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2018 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә шушы Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актларны кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 20 декабрь
№ 103-ТРЗ